«10» ноябрь, 2022 ел № 2

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Кызыл Байрак торак пункты территориясендә гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Кызыл Байрак торак пункты территориясе өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 20000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме,- дигән мәсьәлә буенча 2022 елның 30 октябрендә үткән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Кызыл Байрак торак пунктында Сосновая, Идел буе, Лесная урамнары буенча авыл эчендәге юлларны реконструкцияләү

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 10 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 0 кеше. Кворум юк.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Кызыл Байрак торак пункты территориясендә халык җыены үткәрелмәгән дип танырга.
2. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Кызыл Байрак торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Шилангы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: В.В.Майоров